МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

10.02.2022 Казан ш. № 387-р

**Газ бүлү челтәренең (газүткәргеч) саклау зоналары чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 28.12.2017 № 3135-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, һәм «Земля» РКҮ АҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе хатын истә тотып (19.01.2022 № 63/04), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Газпром трансгаз Казань» милкендә булган, ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Югары Ослан, Яшел Үзән муниципаль районнары һәм «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен урнаштыру турында” 28.12.2017 № 3135-р карары белән (алга таба - № 3135-р Карар) 554,76 м озынлыктагы, 2203 кв.м гомуми мәйданлы 16:15:040101:44, 16:15:040101:43, 16:15:040101:406 кадастр номерлы җир кишәрлекләре өлешләрендәге 67608 инвентарь номерлы газүткәргеч саклау зонасын туктатырга.

2. Югары Ослан муниципаль берәмлеге территориясендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, 67608 инвентарь номерлы газүткәргечнең 579 м озынлыктагы, гомуми мәйданы 2298 кв.м булган саклау зоналарын, газүткәргечне реконструкцияләү сәбәпле, «РКЦ «Земля» АҖ әзерләгән

территорияне кулланунының аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты һәм җир өсте объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге буенча 16:15:040101:44, 16:15:040101:43, 16:15:040101:406 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргеч саклау зонасы чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән 67608 инвентарь номерлы газүткәргечне эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. «РКЦ «Земля» АҖ әзерләгән территорияне кулланунының аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты газүткәргече чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 3135-р карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 02.06.2020 № 1785-р карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан, Яшел Үзән муниципаль районнары һәм «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен урнаштыру турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«1. Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналары чикләрен урнаштырырга: »;

1 пунктның 1.1 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«1.1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан 13,35524 км озынлыктагы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Зеленодольскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ, «Рубикон кадастр үзәге» ААҖ, «Земля» РКҮ» АҖ тарафыннан башкарылган территорияне кулланунының аерым шартлары булган зоналар чикләре урнашуның текстлы һәм график тасвирламасында күрсәтелгән белешмәләргә, газ бүлү челтәрләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегенә туры китереп;

1 нче кушымтада:

67608 инвентарь номерлы газүткәргечкә туры килгән юлны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «67608 | | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Введенско-Слободское авыл | 579 | Түбән басымлы газүткәргеч, җир асты, полиэтилен; | 16-16-01/150/2014-417 от 24.09.2014 16-15-/2001-168.1 от 16.11.2001»; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | җирлеге, Введенская Слобода ав. | | | |

2 нче кушымтада:

16:15:040101:44, 16:15:040101:43, 16:15:040101:406 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә туры килгән юлларны төшереп калдырырга;

әлеге карарга 1 нче кушымтагы юллар белән тулыландырырга.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Н.В.Захаровка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 10.02.2022 № 387-р карарына
**1 нче кушымта**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 67608 инв. газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Введенско-Слободское авыл җирлеге, Введенская Слобода ав., Кояшлы ур. | милек | | 16:15:040101:44 | Торак пунктлар җирләре | 0 | Әхмәтшин Илдар Индус улы | Шәхси ярдәмче хуҗалык |
| 67608 инв. газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Введенско-Слободское авыл җирлеге, Введенская Слобода ав., Кояшлы ур. | милек | | 16:15:040101:43 | Торак пунктлар җирләре | 5,13 | Әхмәтшин Илдар Индус улы | Шәхси ярдәмче хуҗалык |
| 67608 инв. газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Введенско-Слободское авыл җирлеге, Введенская Слобода ав., Кояшлы ур. | милек | | 16:15:040101:406 | Торак пунктлар җирләре | 159,98 | Блажиевский Владимир Владимирович | Шәхси ярдәмче хуҗалык |